Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № №XXVII-2**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 17 гыйнвары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Х. Хәбибуллинның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 маддәсенә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 маддәсенә таянып, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 47,48 маддәләре, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмә хакында” 2010 елның 15 октябрендәге I-4 номерлы, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт проектын раслау турында” 2015 елның 22 сентябрендәге I-4 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә һәм аны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2010 елның 15 октябрендәге I-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә уздырырга.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документларны 2018 елның 19 гыйнварыннан 2018 елның 7 февраленә кадәр ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен 8 дән 17 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул итәргә:422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин ур.,48 йорт.

2. Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләү турында” 2014 елның 22 декабрендәге ПУ-1164 номерлы Указын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе

муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе (алга таба - конкурс комиссиясе) составын кушымта нигезендә расларга.

3. Конкурс комиссиясенә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә 2018 елның 28 февраленә кадәр конкурсны үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләренең кандидатлар турында мәгълүматларын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына тапшырырга.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә “Авыл офыклары” район газетасында конкурс үткәрү турында хәбәрне бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары И.Г. Ибраһимовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2018 елның 17 гыйнварындагы
XXVII-2 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатураларны карау өчен**
**Конкурс комиссиясе составы**

| № | Ф.И.А.и. | Эш урыны, вазыйфасы | Кем тарафыннан билгеләнгән | Комиссия составындагы статусы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Исмәгыйлев Рафаэль Дәүләтьярович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы | Комиссия рәисе |
| 2. | Зарипова Эльмира Әмировна | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министры | Татарстан Республикасы Президенты | Комиссия рәисе урынбасары |
| 3. | Шелкова Светлана Александровна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы | Комиссия сәркатибе |
| 4. | Фәхретдинов Альберт Шамилович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, “Кулон” ябык акционерлык җәмгыяте генераль директоры | Татарстан Республикасы Президенты | Комиссия әгъзасы |
| 5. | Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдифовна | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы | Татарстан Республикасы Президенты | Комиссия әгъзасы |
| 6. | Җамалиев Рөстәм Рәсимович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы | Комиссия әгъзасы |